**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**18.03.2022** **№ 330**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Биектау муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны җайга салу һәм идарә итү системасын оештыру һәм камилләштерү, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының билгеләнгән чикләрендә транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законына, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясына, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән субсидияләр формасындагы грантларга гомуми таләпләр турында, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына

торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе составын (2 нче кушымта);

- Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү комиссиясе турында нигезләмәне (3 нче кушымта);

- Субсидия бирү турында килешүне (4 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУсен Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Түбәндәгеләр үз көчләрен югалткан дип танырга:

- Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 24 июлендәге 1157 номерлы карары;

- Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Башкарма комитетның «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 гыйнварындагы 90 номерлы карары;

- Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Башкарма комитетның «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 30 июлендәге 592 номерлы карары;

- Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Башкарма комитетның «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 26 ноябрендәге 907 номерлы карары;

- Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Башкарма комитетның «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында

йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 16 декабрендәге 983 номерлы карары;

4. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталының Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Хисамутдинов

1 нче кушымта

Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының
18.03.2022 № 330нче номерлы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибе

I. Тәртипне эшләү нигезе һәм субсидияләр бирүнең максатлары

1.1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы һәм Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип, Биектау районы территориясендә автомобиль транспортының җайга салына торган тарифлары буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүне конкурентлык ысуллары белән сайлап алынган юридик затларга (муниципаль учреждениеләргә субсидияләр керми) индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив-хокукый акты белән билгеләнгән күләмдә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субсидияләр хисабына барлыкка килгән Биектау муниципаль районы бюджеты чараларыннан субсидияләр бирү процедурасын һәм шартларын билгели (алга таба – Йөртүче, Субсидияләр).

II. Юридик затлар һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның субсидия бирү хокукына ия категорияләре

2.1. Юридик затларның һәм (яисә) индивидуаль эшкуарларның түбәндәге категорияләре субсидияләр бирүгә дәгъва кылырга хокуклы:

- Россия Федерациясе салым органында тиешле рәвештә теркәлгән;
- 8 (сигез) дән артык кеше йөртү өчен җиһазландырылган автомобиль транспортында пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган.

## III. Субсидияләр бирү шартлары

3.1. Субсидияләр юридик затларга - (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән

тыш), индивидуаль эшкуарларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә (алга таба оешмалар) бирелә, алар түбәндәге критерийларга туры килергә тиеш:

-дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә үткәрелгән башкаручыны билгеләү нәтиҗәләре буенча төзелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә җайга салына торган тарифлар буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуга бәйле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контракт булу;

- Биектау муниципаль районының даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут челтәре буенча пассажирлар йөртү хезмәтләре күрсәтү;

- даими элемтә маршруты буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниесе нигезендә пассажирлар йөртү хезмәтләре күрсәтү;

- Йөртүченең документлар белән расланган төшеп калган керемнәре барлыкка килү;

- салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау;

- Биектау муниципаль районы бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, һәм бюджет алдында башка срогы чыккан бурычы булмау;

-субсидияләр алучылар - юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында булырга тиеш түгел, ә субсидияләр алучы индивидуаль эшкуарлар индивидуаль эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;

- субсидияләр алучылар чит ил юридик затлары булып торырга тиеш түгел, шулай ук теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган мондый юридик затларга карата салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яисә) финанс операцияләре уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территория булган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше 50 процenttан артык булган россия юридик затлары булып торырга тиеш түгел;

- субсидияләр алучылар, әлеге Тәртипнең 1.2 пунктчасында күрсәтелгән максатларга әлеге Тәртип нигезендә, башка муниципаль хокукый актлар нигезендә субсидияләр бирү планлаштырылган Биектау муниципаль районы бюджетыннан акчалар алырга тиеш түгел.

3.2. Бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче һәм субсидия алучы арасында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү турында килешү Россия Федерациясе Финанс министрлыгы, Россия Федерациясе субъектының финанс органы, муниципаль берәмлекнең финанс органы тарафыннан тиешле төр субсидия өчен билгеләнгән типлаштырылган форма (алга таба - килешү) нигезендә төзелә.

3.3. Әлеге Тәртиптә күрсәтелгән субсидияләр бирелгәндә, аларны бирүнең мәҗбүри шарты булып, субсидияләр бирү турындагы шартнамәләргә (килешүләргә)

һәм әлеге шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләргә (килешүләргә) кертелә торган, тиешле тәртиптә, субсидияләр алучыларның һәм субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм аларның устав (тупланма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашы булган җәмгыятьләрдән, шулай ук аларның устав (тупланма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашы булган коммерция оешмаларыннан тыш) субсидияләр биргән бюджет акчаларын баш бүлүче (күрсәтмә бирүче) - Башкарма комитет, һәм муниципаль финанс контроле органы - Контроль-хисап палатасы тарафыннан субсидияләр бирүнең шартларын, максатларын һәм тәртибе алар тарафыннан үтәлүен тикшерүләрне гамәлгә ашыруга ризалыгы тора.

## IV. Субсидияләр бирү тәртибе

4.1. Субсидия алу өчен Йөртүче ай саен, хисап аеннан соң килүче 10 числодан соңга калмыйча, ә декабрьдә 20 числога кадәр Комиссия каравына түбәндәге документларны тапшыра:

- субсидияләр бирү турында гариза;
- йөртүләрне гамәлгә ашырудан төшеп калган керемнәрнең барлыкка килүен раслый торган әлеге тәртиптә билгеләнгән форма буенча исәп (Тәртипкә 1 нче кушымта).

4.2. Йөртүче тарафыннан тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча субсидия бирүгә документларны карау буенча комиссия 10 эш көне эчендә төшеп калган керемнәрне каплауга субсидияләр бирү яисә дәлилләнгән кире кагу турында карар кабул итә, аны беркетмә белән рәсмиләштерә.

4.3. Килешү төзүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 4.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);
- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы;
- Йөртүче тарафыннан тарифларның Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты тарафыннан расланган тарифның иң чик дәрәҗәсенә (алга таба - тарифның иң чик дәрәҗәсе) караганда түбәнрәк кулланылуы.

4.4. Кисәтүләр булган очракта, документлар Йөртүчегә кисәтүләрне бетерү өчен кайтарыла, шул ук вакытта язмача рәвештә документларның кире кайтарылу сәбәпләре чагылдырыла.

Кисәтүләр булган очракта, аларны төзәтү өчен Йөртүчегә бирелгән гомуми вакыт документлар алынган көннән алып 3 календарь көннән артмаска тиеш.

4.5. Субсидияләр күчерү Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты шәхси счетыннан Йөртүче счетына төшеп калган керемнәрне каплауга субсидияләр бирү карар кабул ителгән көннән алып 10 (ун) эш көне эчендә башкарыла.

4.6. Бирелә торган субсидиянең күләме билгеләнгән тәртиптә кимегән очракта (Биектау муниципаль районы бюджетының бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм

чыгымнарын финанслау күләмнәре җитмәгән очракта) киметелергә мөмкин.

4.7. Субсидия бирү Йөртүче тарафыннан субсидия бирү турындагы Килешүдә каралган йөкләмәләр үтәлмәгән яисә тиешенчә үтәлмәгән очракта, автотранспорт предприятиесен бетерү, үзгәртеп оештыру очракларында һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган башка очракларда туктатылырга мөмкин.

## V. Төшеп калган керемнәрне каплау суммасын исәпләү

5.1. Пассажирларны муниципаль маршрутлар буенча йөртүне гамәлгә ашыручы Йөртүченең барлыкка килә торган төшеп калган керемнәрен каплауга субсидия күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча хисап юлы белән билгеләнә:

$$С = З - Д$$

монда:

С – субсидияләр күләме, мең сум;

З - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 гыйнварындагы 61 номерлы карары белән расланган, транспорт чарасы классына (1 километр өчен 43 сум 05 тиен) һәм маршрутның озынлыгына бәйле рәвештә, 1 км ара узуның иң чик норматив үзкыйммәтен исәпкә алып, җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә автомобиль транспорты белән муниципаль маршрутларында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга чыгымнар;

Д - җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча йөргән өчен түләүдән алынган керемнәр, мең сум.

Перевозчик керемнәре составында керемнәрнең түбәндәге төрләре исәпкә алына:

- пассажирлар йөрүгә һәм багаж ташуга муниципаль йөртүләр вакытында бер тапкыр бирелә торган билетларны сатудан кергән акча;

- гражданнарның социаль юл билетлары буенча ташламалы категорияләрен йөртүгә бәйле барлык дәрәҗәләрдәге бюджетлардан бирелә торган Йөртүченең чыгымнарын компенсацияләү суммалары.

Шул ук вакытта Йөртүченең керемнәре автобусның тулу коэффициентын, 2022 елда - 0,5 һәм көненә кимендә ике әйләнеш рейска тигез булган куллануны исәпкә алып хисаплана.

## VI. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

6.1. Йөртүчеләр субсидияләр рәвешендә алынган бюджет акчаларын бирелгән документларны тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән төшеп калган керемнәрнең нигезсез булуы ачыкланган очракта, шулай ук башка контроль чаралар уздыру нәтиҗәсендә, фактта барлыкка килгән төшеп калган керемнәр өстеннән төшеп калган керемнәрне нигезсез рәвештә күрсәтү күләмендә кире кайтарырга тиеш.

Субсидияләрне кире кайтару Биектау муниципаль районы бюджетыннан Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларыннан гамәлгә ашырыла торган компенсация түләүләрен каплауга субсидияләр арттырылган очракта гамәлгә ашырыла.

6.2. Ачыкланган хокук бозулар комиссия тарафыннан имзаланган акт белән рәсмиләштерелә һәм Йөртүчегә - субсидияләр алучыга бирелә.

6.3. Акт алынган көннән алып 30 календарь көннән дә артык булмаган вакыт эчендә Йөртүче Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетына агымдагы финанс елында тиешеннән артык алынган акчаларны кире кайтарырга тиеш.

6.4. Кире кайтарылган субсидияләр суммасы Биектау муниципаль районы бюджеты керемнәренә күчерелергә тиеш.

6.5. Субсидияләр кире кайтарылмаган очракта, вәкаләтле орган кире кайтарылырга тиешле бюджет акчаларын суд тәртибендә түләтү чараларын күрә.

## VII. Контроль

7.1. вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органы субсидияләрдән файдалану шартларының, максатларының һәм тәртибенең оешмалар тарафыннан үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыралар.

7.2. Субсидияләр бирү шартларын бозу яисә аларны максатчан файдаланмау ачыкланган очракта, субсидияләр Вәкаләтле органның язма таләбе буенча субсидияләр алучы тарафыннан бер ай эчендә Биектау муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш. Субсидия билгеләнгән срокта кире кайтарылмаган очракта, ул Биектау муниципаль районы бюджеты керемենә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта

20___елның __________________________________ өчен Биектау муниципаль
(ае, кварталы)
районы муниципаль даими автобус маршрутларында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы ________________________________________________________________
(автотранспорт предприятиесе)
төшеп калган керемнәрен каплау суммасы

ИСӘП-ХИСАБЫ

| Маршрутның исеме | Хисап чорында пассажирлар саны, кеше. (торак пунктлар киселешендә) | Икътисадый нигезләнгән тариф, сум | Пассажирлар йөртүдән алынган керемнәр, сум. | | СПБ буенча барган өчен компенсация суммасы, сум. | Капланырга тиешле төшеп калган керемнәрне каплау суммасы, сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Бер тапкыр бирелә торган билетлар, сум. | Социаль билетларны да кертеп, айлык юл билетлары, | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |
| БАРЛЫГЫ | | | | | | |

Оешма җитәкчесе __________________/__________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

Башкаручы ____________________/____________________
(вазыйфа) (имза) (тулы имза)

2 нче кушымта
Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының
18.03.2022 № 330нче номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| 1. Хәкимуллин Рамил Фатыйх улы | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| 2. Булгаков Мурад Рамил улы | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Комиссия секретаре: | |
| 3. Тарасова Алина Сергеевна | Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенең баш белгече; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| 4. Ганиева Валентина Анатольевна | Исәпкә алу һәм хисаплылык бүлеге башлыгы; |
| 5. Таҗиев Илдар Илгизәр улы | «ТР БМР Советы» МО МКУнең юридик бүлеге башлыгы |

3 нче кушымта
Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының
18.03.2022 № 330нче номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү буенча комиссия алда күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү турында гаризаларны карый.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссиянең төп бурычы булып Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортының муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тора.

4. Комиссия хокуклы:

- субсидияләр алучылардан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортының муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибендә күрсәтедгән тиешле документларны соратып алырга.

5. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары аның утырышында алмаштыру хокукыннан башка катнаша. Комиссия әгъзасы, утырышта ул булмаган очракта, карала торган мәсьәләләр буенча язма рәвештә үз фикерен бәян итәргә хокуклы.

6. Комиссия карарлары утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аны комиссия рәисе һәм әгъзалары имзалый.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарның бер өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә 4 нче кушымта

Субсидия бирү турында
КИЛЕШҮ

«_____»__________, 2022 ел

Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Хисамутдинов Равил Фәрит улы йөзендә, Нигезләмә нигезендә эш итүче, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты, алга таба «Башкарма комитет» дип аталачак, бер яктан, һәм ______________________ йөзендә, ______________________________________ нигезендә эш итүче _________________________________, алга таба «Йөртүче» дип аталучы, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр:

**1. Килешүнең предметыредмет**

1.1. Килешү предметы булып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында даими йөртү муниципаль маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы Йөртүченең барлыкка килә торган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә уза торган муниципаль маршрутлар буенча автомобиль транспортында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында субсидияләр бирү тора.

1.2. Субсидия күләме Йөртүче тарафыннан тапшырылган исәп-хисаплар һәм документлар нигезендә комиссия тарафыннан раслана.

1.3. Бирелә торган субсидияләр катгый максатчан билгеләнештә була һәм әлеге Килешүнең 1.1 пунктында каралмаган максатларда файдаланыла алмый.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Башкарма комитет бурычлы:

2.1.1. Субсидия бирүгә документларны карау комиссиясе әгъзалары белән берлектә (алга таба - Комиссия) әлеге Килешү нигезендә тапшырылган финанс документларын тикшерергә һәм хаталар ачыкланган очракта аларны кире кайтарырга.

2.1.2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының шәхси счетыннан Йөртүче счетына төшеп калган керемнәрне каплауга акчаны Комиссия субсидияләр бирү турында кул куйган көннән соң 10 (эш) эш көне эчендә күчерергә.

2.2. Башкарма комитетхокуклы:

2.2.1. Йөртүченең бухгалтерлык исәбе мәгълүматлары буенча субсидияләр алуга тәкъдим ителгән исәп-хисапларның туры килүен тикшерүне гамәлгә ашырырга.

2.2.2. Әлеге Килешүнең шартлары Йөртүче тарафыннан бозылган очракта, бу хакта язма рәвештә икенче якны 10 көннән дә соңга калмыйча кисәтеп куеп, Килешүне үтәүдән берьяклы тәртиптә баш тартырга.

2.3. Йөртүче бурычлы:

2.3.1. Эшчәнлекнең субсидияләнүче төрләре буенча керемнәрнең һәм чыгымнарның аерым исәбен алып барырга.

2.3.2. Хисап аеннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, ә декабрьдә 20 числога кадәр Комиссия каравына гамәлдәге Тәртип нигезендә субсидия алу хокукын раслый торган документларны тапшырырга:

- субсидияләр бирү турында гариза;

- Биектау муниципаль районының муниципаль даими автобус маршрутларында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы предприятиенең төшеп калган керемнәрен каплау суммасы исәп-хисабы (Тәртипкә 1 нче кушымта);

- Биектау муниципаль районында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча йөргән өчен түләүдән алынган предприятие керемнәре исәп-хисабы (Тәртипкә 2 нче кушымта);

- транспорт чаралары тулышының 50 %ын исәпкә алып, Биектау муниципаль районында җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары буенча йөрү өчен түләүдән алынган предприятие керемнәре исәп-хисабы (Тәртипкә 3 нче кушымта);

2.3.3. Тапшырылган дөрес булмаган документлар һәм (яисә) бирелгән субсидияләрне максатчан файдаланмау факты билгеләнгән вакыттан алып, 30 календарь көн эчендә алынган субсидияләрне кире кайтаруны гамәлгә ашырырга.

2.4. Йөртүче хокуклы:

2.4.1. Тәртип нигезендә һәм шушы Килешү нигезендә субсидия алырга.

2.5. Йөртүче хокуктан баш тартырга һәм үз йөкләмәләрен Килешү буенча күчерү хокукына ия түгел.

## 3. Исәп-хисап тәртибе

3.1. Субсидия Йөртүчегә Комиссия тарафыннан расланган суммада бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, Йөртүченең исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

## 4. Якларның җаваплыгы

4.1. Башкарма комитет җаваплы:

- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә шәһәр яны муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджеты акчаларыннан субсидияләр бирү тәртибен үтәү өчен;
- Исәп-хисапларны һәм документларны карау срокларын, шулай ук Йөртүчегә субсидия түләү срокларын үтәү өчен.

4.2. Йөртүче субсидияләр алуга өчен тапшырылган исәп-хисапларның дөреслеге һәм максатчан файдаланмаган өчен җаваплы.

4.3. Субсидияләрне бирү шартлары, максатлары һәм кагыйдәләре Йөртүче тарафыннан бозылган очракта, бюджет акчалары Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җирле бюджетка кайтарылырга тиеш.

4.4. Бирелгән субсидияне кире кайтару Йөртүче тарафыннан, субсидияләрне кире кайтару турындагы таләп куелган көннән алып, 30 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

## 5. Килешүнең гамәлдә булу срогы

5.1. Әлеге Килешү аны имзалаганнан вакыттан үз көченә керә һәм ______ елның _____ га кадәр гамәлдә.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Йөртүче Тәртиптә каралган субсидияләр бирүнең шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне Башкарма комитет һәм (яисә) муниципаль финанс контроле органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүгә ризалыгын белдерә.

6.2. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр бары тик язма рәвештә рәсмиләштерелгән һәм ике якның да вәкаләтле вәкилләре тарафыннан имзаланган очракта гына гамәлдә була.

6.3. Әлеге Килешү буенча яисә аңа бәйле рәвештә яклар арасында барлыкка килә торган барлык бәхәсләр һәм каршылыклар яклар арасында сөйләшүләр юлы белән хәл ителә. Төрле каршылыкларны сөйләшүләр юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, бәхәсләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

6.4. Әлеге Килешү тигез юридик көчкә ия ике нөсхәдә төзелде.

## 7. Юридик адреслар һәм банк реквизитлары

| | |
|---|---|
| Биектау муниципаль районы<br>Башкарма комитеты | Йөртүче |